**ОПРЕДЕЛЕНИЕ**
КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Л.П. Павлухина на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1.1 и разделом 4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан»**

город Казань 10 июня 2019 года

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина Л.П. Павлухина,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин Л.П. Павлухин с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1.1 и разделом 4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006

года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» (далее также — Положение).

Оспариваемый пункт 1.1 указанного Положения устанавливает, что данное Положение регламентирует порядок и условия предоставления субсидий отдельным категориям граждан, имеющим право на скидку в оплате жилья и коммунальных услуг в соответствии с законодательствами Российской Федерации и Республики Татарстан (далее – субсидии-льготы), а раздел 4 определяет механизм предоставления субсидии-льготы.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что гражданин Л.П. Павлухин является инвалидом и ветераном труда, проживает совместно со своей супругой, которая является также ветераном труда, в частном доме в пгт. Нижние Вязовые Зеленодольского района Республики Татарстан. Ему, как инвалиду, на основании Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» в 2016 году назначена субсидия-льгота на оплату жилья и коммунальных услуг. За период с ноября 2017 года у заявителя образовалась задолженность по оплате коммунальных услуг.

Как отмечает в своей жалобе гражданин Л.П. Павлухин, указанная задолженность возникла по той причине, что начисляемая ему субсидия поступает на его расчетный счет после срока оплаты им жилого помещения и коммунальных услуг. Решением мирового судьи судебного участка № 8 по Зеленодольскому судебному району Республики Татарстан, оставленным без изменения апелляционным определением Зеленодольского городского суда Республики Татарстан исковые требования АО «Татэнергосбыт» в лице филиала «Буинское отделение» к нему о взыскании задолженности за потребленную электроэнергию были удовлетворены. Определением судьи Верховного суда Республики Татарстан заявителю было отказано в передаче кассационной жалобы для рассмотрения в судебном заседании кассационной инстанции Верховного суда Республики Татарстан.

По мнению гражданина Л.П. Павлухина, обжалуемый пункта 1.1

Положения, исходя из своего буквального содержания, не регламентирует порядок и условия предоставления субсидий-льгот инвалидам, поскольку как он считает, инвалиды относятся к категории граждан, имеющих право на скидку в оплате жилья и коммунальных услуг в соответствии с законодательством Российской Федерации. Вместе с этим, он отмечает, что слово «отдельным» в оспариваемой норме не указывает на инвалидов, подпадающих под действие названного Положения. Ему неясно, в соответствии с каким нормативным актом в Республике Татарстан предоставляются субсидии-льготы на оплату жилья и коммунальных услуг на основании Федерального закона «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации».

Кроме этого, раздел 4 обжалуемого Положения, как утверждает заявитель, устанавливая механизм предоставления субсидии-льготы, не определяет, когда она предоставляется: до срока внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги или после и возможно ли за счет субсидий производить оплату жилого помещения и коммунальных услуг.

В своей жалобе гражданин Л.П. Павлухин указывает, что в силу неопределенного содержания раздела 4 Положения порядок оплаты жилого помещения и коммунальных услуг субсидиями оставлен на произвольное решение правоприменительного органа, который фактически ничем не ограничен в своем усмотрении и может предоставить субсидию-льготу как до срока внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги, так и после наступления этого срока. Тем самым реальный механизм предоставления субсидии-льготы в разделе 4 Положения отсутствует.

На основании изложенного заявитель просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 1.1 и раздел 4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», не соответствующими статьям 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 48

(часть вторая), 54 (часть первая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с частью 1 статьи 160 Жилищного кодекса Российской Федерации отдельным категориям граждан в порядке и на условиях, которые установлены федеральными законами, законами субъектов Российской Федерации и нормативными правовыми актами органов местного самоуправления, могут предоставляться компенсации расходов на оплату жилых помещений и коммунальных услуг за счет средств соответствующих бюджетов.

На основании Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» (в редакции Федерального закона от 29 декабря 2004 года № 199-ФЗ) полномочия по предоставлению мер социальной поддержки инвалидов по оплате жилого помещения и коммунальных услуг с 1 января 2005 года переданы органам государственной власти субъектов Российской Федерации (статья 28.2, часть 1). Данным Федеральным законом также предусмотрено, что форма предоставления указанных мер социальной поддержки определяется нормативными правовыми актами субъектов Российской Федерации (статья 28.2, часть 6).

В рамках реализации Федерального закона от 22 августа 2004 года № 122-ФЗ «О внесении изменений в законодательные акты Российской Федерации и признании утратившими силу некоторых законодательных актов Российской Федерации в связи с принятием Федеральных законов «О внесении изменений и дополнений в Федеральный закон «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» и «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» и в силу указанных выше норм федерального законодательства, Кабинет Министров Республики Татарстан постановлением от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» утвердил Положение о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан.

Оспариваемый заявителем пункт 1.1 Положения исходя из его содержания направлен на определение предмета регулирования Положения, а именно регламентацию порядка и условий предоставления субсидий отдельным категориям граждан, имеющим право на скидку в оплате жилья и коммунальных услуг. Что касается категории граждан, которым предоставляются субсидии на оплату жилья и коммунальных услуг, то необходимо отметить, что во исполнение Федерального закона от 27 июля 2010 года № 210-ФЗ «Об организации предоставления государственных и муниципальных услуг» и в целях реализации обжалуемого постановления Кабинета Министров Республики Татарстан приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 19 ноября 2014 года № 634 утвержден Административный регламент предоставления государственной услуги по назначению субсидии-льготы на оплату жилого помещения и коммунальных услуг, которым к категориям граждан, имеющим право на получение субсидии-льготы отнесены и инвалиды (подпункт 11 пункта 1.2).

Таким образом, пункт 1.1 Положения не содержит неопределённости в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан, поскольку пункт 1.1 подлежит применению в системном единстве с иными нормами федерального и республиканского законодательства, относящих инвалидов к категории граждан, обладающих правом на предоставление мер социальной поддержки.

Что касается вопроса об отсутствии в разделе 4 Положения конкретных сроков предоставления субсидии-льготы по оплате жилья и коммунальных услуг следует отметить, что сам по себе рассматриваемый раздел направлен на определение способа получения гражданами субсидии-льготы и возможности выбора такими гражданами наиболее удобного способа ее получения. Оспариваемый заявителем раздел 4 Положения, как и само Положение в целом, находится в системной взаимосвязи с постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20, регулирующим Порядок информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат. В силу подпункта 20 пункта 6 вышеуказанного

Порядка перечисление субсидий на оплату жилого помещения, коммунальных услуг производится в срок до 9 числа месяца ее выплаты. Тем самым такое правовое регулирование не препятствует гражданам производить оплату за жилое помещение и коммунальные услуги за счет указанной субсидии-льготы. На этом основании довод заявителя о том, что в разделе 4 Положения отсутствует срок предоставления субсидии-льготы по оплате жилья и коммунальных услуг, является необоснованным.

Таким образом, обжалуемые нормы Положения сами по себе не могут рассматриваться как нарушающие конституционные права граждан, в том числе гражданина Л.П. Павлухина, и, следовательно, не содержат неопределенности в вопросе об их соответствии Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявителя не является допустимой.

Исследование обстоятельств образовавшейся задолженности по оплате жилого помещения  и коммунальных услуг у заявителя, а также вопроса о конкретных сроках поступления субсидии на его счет не относятся к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, поскольку в силу части девятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан решает исключительно вопросы права и при осуществлении конституционного судопроизводства воздерживается от установления и исследования фактических обстоятельств во всех случаях, когда это входит в компетенцию других судов или иных органов государственной власти Республики Татарстан.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Л.П. Павлухина на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1.1 и разделом 4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленных заявителем вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину Л.П. Павлухину и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**№ 19-О**

**Конституционный суд**
**Республики Татарстан**

ТАТАРТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәнең 1.1 пункты һәм 4 бүлеге белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Л.П. Павлухин шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2019 елның 10 июне

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Л.П. Павлухин шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Л.П. Павлухин «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм

шартлары турында Нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 1.1 пункты һәм 4 бүлеге белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Күрсәтелгән Нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган 1.1 пунктында билгеләнгәнчә, әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә ташламага хокукы булган гражданнарның аерым категорияләренә субсидияләр (алга таба — ташлама-субсидияләр) бирү тәртибен һәм шартларын регламентлаштыра, ә 4 бүлек ташлама-субсидияләр бирү механизмын билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Л.П. Павлухин инвалид һәм хезмәт ветераны, шулай ук хезмәт ветераны булган хатыны белән бергә Татарстан Республикасының Яшел Үзән районы Түбән Вязовые шәһәр тибындагы поселогында шәхси йортында яши. Аңа, инвалид буларак, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2016 елда торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия билгеләнгән. 2017 елның ноябреннән бирле мөрәҗәгать итүченең коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә бурычлары барлыкка килгән.

Гражданин Л.П. Павлухин үзенең шикаятендә билгеләп үткәнчә, әлеге бурыч үзенә исәпләнгән субсидиянең торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү срогыннан соң гына аның исәп-хисап счетына кертелүе сәбәпле килеп чыккан. Татарстан Республикасы Яшел Үзән суд районы буенча 8 нче суд участогы җәмәгать судьясы карары белән, Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәр судының апелляция билгеләмәсе үзгәрешсез калдырылып, «Буа бүлекчәсе» филиалы аша «Татэнергосбыт» АҖнең аңа кулланылган электр энергиясе өчен бурычларын түләтү турындагы дәгъва таләпләре канәгатьләндерелгән. Татарстан Республикасы Югары суды судьясы билгеләмәсе белән мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы Югары суды

кассация инстанциясенең суд утырышында карау өчен кассация шикаятен тапшырудан баш тартылган.

Гражданин Л.П. Павлухин фикеренчә, шикаять белдерелә торган Нигезләмәнең 1.1 пункты, үзенең турыдан-туры эчтәлегеннән чыгып, инвалидларга ташлама-субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын регламентлаштырмый, чөнки, ул санаганча, инвалидлар Россия Федерациясе законнары нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама алу хокукы булган гражданнар категориясенә керә. Шуның белән бергә, ул, дәгъва белдерелә торган нормада «аерым» сүзе әлеге Нигезләмәгә туры килгән инвалидларны күрсәтми, дип билгеләп үтә. Аңа «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында нинди норматив акт нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирелүе аңлашылмый.

Моннан тыш, шикаять белдерелә торган Нигезләмәнең 4 бүлеге, мөрәҗәгать итүче раславынча, ташлама-субсидияләр бирү механизмын билгеләп, аның кайчан бирелгәнен билгеләми: торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү срогы чыкканчыга кадәрме яки аннан соңмы һәм субсидияләр хисабына торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләргә мөмкинме.

Үзенең шикаятендә гражданин Л.П. Павлухин Нигезләмәнең 4 бүлегендәге билгесезлек нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен субсидияләр белән түләү тәртибе асылда берни белән дә чикләнмәгән хокук куллану органының ирекле карарына калдырылган, дип күрсәтә һәм ул торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү вакытына кадәр дә, шул вакыт җиткәннән соң да ташлама-субсидия бирә ала. Шуның белән Нигезләмәнең 4 бүлегендә ташлама-субсидияләр бирүнең реаль механизмы юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

карары белән расланган Нигезләмәнең 1.1 пунктын һәм 4 бүлеген Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 48 (икенче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 160 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә киткән чыгымнарны компенсацияләү өчен  тиешле бюджет акчалары исәбеннән бирелергә мөмкин.

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (2004 елның 29 декабрендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 2005 елның 1 гыйнварыннан торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә инвалидларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча вәкаләтләр Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган (28.2 статья, 1 өлеш). Әлеге Федераль закон белән шулай ук социаль ярдәмнең күрсәтелгән чараларын бирү формасы Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары белән билгеләнә дип каралган (28.2 статья, 6 өлеш).

«Федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында һәм югарыда күрсәтелгән федераль закон нормалары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак

һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәне раслады.

Мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган Нигезләмәнең 1.1 пункты аның эчтәлегеннән чыгып, Нигезләмәне җайга салу предметын билгеләүгә, атап әйткәндә, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама хокукы булган гражданнарның аерым категорияләренә субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын регламентлауга юнәлдерелгән. Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирелә торган гражданнар категориясенә килгәндә, шуны да билгеләп үтәргә кирәк: «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының шикаять белдерелә торган карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы белән торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты расланган, ташлама-субсидияләр алу хокукына ия гражданнар категориясенә инвалидлар да кертелгән (1.2 пунктның 11 пунктчасы).

Шулай итеп, Нигезләмәнең 1.1 пунктында аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе турындагы мәсьәләдә билгесезлек юк, чөнки 1.1 пункты инвалидларны социаль ярдәм чаралары бирү хокукына ия булган гражданнар категориясенә караган федераль һәм республика законнарының башка нормалары белән системалы бердәмлектә кулланылырга тиеш.

Нигезләмәнең 4 бүлегендә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча ташлама-субсидияләр бирүнең конкрет сроклары булмау мәсьәләсенә килгәндә, каралучы бүлек үзе гражданнар тарафыннан ташлама-

субсидияләр алу ысулын һәм мондый гражданнар тарафыннан аны алуның иң уңайлы ысулын сайлау мөмкинлегенә юнәлдерелгән булуын билгеләп үтәргә кирәк. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Нигезләмәнең 4 бүлеге, тулаем Нигезләмә кебек үк, торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибен җайга сала торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән системалы элемтәдә тора. Югарыда күрсәтелгән Тәртипнең 6 пунктындагы 20 пунктчасы нигезендә торак, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидияләр күчерү айның 9 числосына кадәр башкарыла. Шуның белән мондый хокукый җайга салу гражданнарга күрсәтелгән ташлама-субсидияләр хисабына торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә комачауламый. Шул нигездә, мөрәҗәгать итүченең Нигезләмәнең 4 бүлегендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча ташлама-субсидияләр бирү срогы булмавы турындагы дәлиле нигезсез.

Шулай итеп, шикаять белдерелә торган Нигезләмә нормалары үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән гражданин Л.П. Павлухинның конституциячел хокукларын бозучы буларак карала алмый һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте мөмкин түгел.

Мөрәҗәгать итүчедә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча барлыкка килгән бурычларны тикшерү, шулай ук аның исәбенә субсидия күчерүнең конкрет сроклары турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан

Республикасы Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары яисә башка судлар компетенциясенә кергән барлык очракларда да, конституциячел суд эшләрен гамәлгә ашырганда фактлагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәнең 1.1 пункты һәм 4 бүлеге белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Л.П. Павлухин шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять бирелергә мөмкин түгел, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Әлеге шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Л.П. Павлухинга һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды

хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 19-О**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**